Нәсыйхәт

җомга
17
август
2012 №17

Рәхимле вә Шәфкатьле АЛЛАҺ исеме белән
Мамадыш мәдрәсәсенең айлык дини-иҗтимагый газетасы

## Яңалыклар

**МӘДРӘСӘДӘ ИФТАРЛАР**

10нчы августа Мамадыш мәдрәсәсе ир-атларны иганәчеләр ярдәме белән оештырылган ифтарга җыйды. Җитмешләп кеше килде. 14нче августта биредә хатын-кызлар кунак булды. Мәҗлесне мәдрәсә җитәкчесе Габдрахман хәзрәт ачып җибәрде. Ураза тотуның әһәмияте, Рамазан шәриф аеның фазыйләтләре турында сөйләде һәм ураза тотучыларга сабырлыклар теләде, әлеге изге айда күбрәк изге гамәлләр кылырга чакырды.

**ЯҢА УКУ ЕЛЫНА ӘЗЕРЛЕК**

Мәдрәсә бинасында яңа уку елына әзерлек бара. Уку җиһазлары ремонтлана, буяу һәм чистарту, уку бүлмәләрен төзекләндерү эшләре алып барыла. Авырлыкларга карамыйча, бу эшләрне мәдрәсә үз көче белән башкара.

**МӨГАЛЛИМНӘР– КӨТЕЛГӘН КУНАК**

Мәдрәсә мөгаллимнәре районның төрле авылларында уза торган ифтар мәҗлесләрендә актив катнаштылар. Халыкның сорауларына җавап бирделәр, файдалы вәгазь-нәсыйхәтләрен сөйләделәр, мәдрәсәгә укырга чакырдылар.

**"ӨМЕТ"КӘ ЯРДӘМ**

11нче августта мәдрәсә җитәкчелеге "Өмет" социаль приютында кунакта булды. Балалар алар алып килгән җиләк-җимеш белән сыйландылар, үгет-нәсыйхәтләрне игътибар белән тыңладылар.

**КОНГРЕССТА КАТНАША**

Мәдрәсә мөгаллиме Ирек хәзрәт Нуриев 29нчы августта Казанда узачак Бөтендөнья татар конгрессында катнашачак. Өч көн дәвам итәчәк чарада татар дөньясында булган актуаль мәсьәләләр каралачак.

Мөхәррир сүзе

# Бәйрәмебез мөбарәк булсын!



**Безне һидаяткә күндергән, күңелләребезгә иман нурын иң зиннәтле нәрсә итеп урнаштырган Аллаһы Тәгаләгә барча мактауларыбыз булсын. Пәйгамбәребезгә рәхмәт-салаватларыбыз, сәхәбәләренә, аңа изгелектә иярүчеләргә догаларыбыз барып ирешсен.**

Хөрмәтле мөселманнар! Түземсезлек белән көтеп алынган Рамазан ае да ахырына якынлаша. Рамазан ае безгә бик күп кыйммәтле дәресләр бирде. Нәфесне тыярга, күңелне пакьләргә, хайван сыйфатларын җиңәргә, Аллаһ белән якынаерга ярдәм итте. Әмма Рамазан ае китә дип без изгелекләр кылудан туктамаска тиешбез. Әйе, бу айда без бихисап зур дәресләр алабыз. Әмма һәркайсыбыз да дәресебезне гомеребез буе үтәргә тырышсак иде. Чөнки калган 11 ай да Аллаһныкы. Ул айларда да гөнаһ кылырга рөхсәт юк. Ураза тоту Рамазан белән генә чикләнми, безнең башка айларда да күп нәфел уразаларыбыз бар. Шәүвәл аенда 6 көн, һәр айның уртасында 3 көн, дүшәмбе һәм пәнҗешәмбе көннәрендә һәм гашура уразалары, калган айларда да Коръән Кәрим уку, һәр ай саен бер хәтем кылу Рәсүлебезнең сөннәтеннәндер. Калган айларда да фәкыйрьләрнең ризыкка мохтаҗ булуларын исебездән чыгармыйк.

Шуны онытмыйк, калган көннәрдә дә Раббыбыз безгә үзенең нигъмәтләрен бирүен дәвам итә. Һәм ул нигъмәтләр чиксез. Шуңа күрә дә без бүтән айларда да Бөек Хуҗабызныданларга һәм аңа шөкер итәргә тиешбез.

Хөрмәтле районлашлар! Рамазан ае безгә юмартлык дәресләрен дә бирде. Шунлыктан Раббыбызның ачуын китерә торган саранлыгыбыздан арынсак иде. Бүгенге көндә мәдрәсә яңа уку елына әзерләнә. Ел дәверенә шәкертләрне ризык белән тәэмин итү, укытучыларга хезмәт хаклары түләү өчен финанс булдыру җиңел түгел. Һәм бу эштә бергә һәм бердәм булсак кына гамәлләребез нәтиҗәле булыр. Мәдрәсәбезне ятим итмик, маллрыбызны кызганмыйк, көчебездән килгәнчә гошер һәм зәкәтләребез белән гыйлем йортына ярдәм итик.

Мөхтәрәм җәмәгать! Җәнәбел Хак эшләгән барча яхшылыкларыбызны кабул итсен. Иманга яңа килүчеләргә иманнарын арттырырга, гыйлем эстәүчеләргә хәерле, файдалы гыйлемнәр алырга насыйп әйләсен. Балаларыбызга изге ният белән гамәл кылып, киләчәктә динебезгә, ватаныбызга, милләтебезгә хәерле хезмәтләр күрсәтергә көч-куәт бирсен. Безгә сабырлыкны, күркәм холыкны, ихтирамны, күркәм мөгамәләне юлдаш кылсын.

Хөрмәтле кардәшләр! Раббыбыз, тормышларыбызның һәр көнен Рамазан шәриф аендагы кебек бәхетле, чиста һәм ихласлы, ә төннәребезне Кадер кичләре кебек зекер һәм истигъфарлы итеп үткәрергә насыйп әйләсә иде.

Раббыбыз тоткан уразаларыбызны кабул итсә иде! Киләчәк Рамазан аен да исәнлектә каршы алып, уразаларны тотарга насыйп итсә иде! Раббыбыз барча галәмгә муллык вә сәгадәт насыйп әйләсен! Гает бәйрәмебез мөбарәк булсын!

**Габдрахман хәзрәт ХӘБИБУЛЛИН**

## Төрлесеннән



**ДМИТРИЙ МЕДВЕДЕВ ТАТАРСТАН МӨФТИЕН УРАЗА ГАЕТЕ БЕЛӘН КОТЛАДЫ** (Котлау сүзләрен Татарстан мөселманнары Дини нәзарәте үз сайтында бастырган.)

**ТӨРКИЯНЕҢ ИСТАНБУЛ ШӘҺӘРЕНДӘ “СӨЛӘЙМАНИЯ” АРХИТЕКТУРА ЯГЫННАН ИҢ МАТУР МӘЧЕТ.** Дүрт манаралы мәчет манаралары арасына “AFFET ALLAHIM” – “Гафу ит, Аллаһым” дигән ут урнаштырылган.

**МАРАТ ГАТИН “КОЛ ШӘРИФ” МӘЧЕТЕ ӨЧЕН ҖАВАПЛЫ.** Татарстан Республикасы Президентының дини берләшмәләр белән хезмәттәшлек идарәсенең элекке башлыгы Марат Гатин “Казан Кремле” музейтыюлыгы директоры Зилә Вәлиева урынбасары вазифасына билгеләнгән.

**ТӨП ГАЕТ “КОЛ ШӘРИФ”ТӘ УЗАЧАК.** 19 августта Татарстанның барлык мәчетләрендә гает вәгазе иртәнге сәгать 6.00 дә, Казанның “Кол Шәриф” мәчетендә сәгать 7.00 дә башлана. Бирелә уздырылачак төп бәйрәм чарасы “Татарстан-Яңа гасыр” каналыннан күрсәтеләчәк.



**Без беләбез: гыйбадәтнең күренә торган һәм күренми торган ягы бар (формаль һәм яшерен ягы).**

Идеалда бу ике як бер-берсеннән аерылмаска тиеш. Һәр гыйбадәтнең асылы булып ихласлылык тора. Бу шуны аңлата: гыйбадәтне бары тик Аллаh боерганы өчен генә һәм аның ризалыгы өчен генә кылырга. Әгәр кеше башка уй белән намаз укый икән, бу вакытта кылган гыйбадәте юкка чыга. Гыйбадәтнең физик якка, ягъни сәламәтлеккә булган файдасы кешегә бары тик стимул гына биреп торырга, төп сәбәп булып тормаска тиеш. Тышкы яктан бөтен шартларга туры китерелеп укылган намаз Аллаh тарафыннан кабул булмыйча, киресенчә чын күңелдән хаталар белән укылганы кабул булырга мөмкин. Моннан нәтиҗә итеп әйтергә кирәк: без намазыбызның тышкы ягы белән бергәттән рухи ягы турында да кайгыртырга, һаман камилләштерергә омтылырга тиеш.
Кешенең нияте шундый зур көчкә һәм әһәмияткә ия. Сөекле пәйгамбәребез (с.г.в.) әйтте: “Гамәлләр ниятка карап бәяләнә”.
Чисталык, ихласлылык, хушуглык, Аллаһтан курку хисе һәм ышаныч, мәхәббәт белән гыйбадәт кылу намазыңның дәрәҗәсен күтәрә. Аллаh Тәгалә әйтте: “Ий Мөхәммәд г-м, Без сиңа Коръәнне хаклык белән индердек, динне ширек вә риядан пакьләп Аллаһының Үзенә генә ихлас гыйбадәт кыл!”. **(39 : 2)**
Әгәр дә кешегә карасак, ул дөньяда булган барлык әйберләрдән дә өстен куелган, бөтенесе дә кешелек өчен ниндидер бер ярдәм китерә, ә үзенә кирәк әйберләрне көч ярдәмендә булдыру сәләтенә килсәк, аның дәрәҗәсе ниндидер бер чыпчыктан да түбәнрәк. Моннан күренгәнчә, кеше хайвани теләкләрен канәгатьләндерү өчен түгел, ә бөек бер максат белән яратылган, ул җир йөзенә Аллаһның илчесе булып килгән. Бу җир йөзе аның өчен бер басу кыры кебек, димәк мондагы уңыш мәңгелеккә җибәрелсен өчен. Кеше үзе бик мохтаҗ зат, аның капиталы нольгә якын, төрле кайгыхәсрәтләргә очрап, сыналып тора. Шушы вакытларда ул үзенең көчсезлеген күрә дә инде. Ә хыял-теләкләренең иге-чиге юк. Әгәр дә кеше “дөм сукыр” түгел икән, ул Аллаһка гыйбадәтнең нинди зур нигъмәт икәнен күрәчәк. Гыйбадәт чын күңелдән, аңлап, төшенеп кылынганда гына дәрәҗәле була дидек. Менә шул вакытта гына ул котылу капкасы булып тора. “1. Тәхкыйк хак мөэминнәр газабтан котылып мәңгелек сәгадәткә ирештеләр.
2. Алар намазларын хошугъ белән укыйлар, Аллаһыдан куркып, кечерәяләр.” **(23 : 1-2).** Пәйгамбәребез( с.г.в.) әйтте: “Кеше Аллаһы Тәгалә

# НАМАЗ



каршында үзенең кылган намазына карап бәяләнә”. Икенче бер хәдисендә әйтә: “Кыямәт көнендә кешегә иң беренче намазы өчен җавап бирергә туры киләчәк, әгәр дә намазында кимчелек булмаса, ә инде кимчелекләре булса, үзенең фәрештәләренә әйтәчәк: “Минем колымның нәфел намазлар бармы, булса, фарызларын тутырыгыз”, – дип. (Бу хәдисне Әхмәд тапшырды).
Пәйгамбәребезнең (с.г.в.) бөтен тормыш юлы безгә юл күрсәтүче маяк булып тора. Гайшә (р.г.) әйтте: “Аллаһның илчесе (с.г.в.) безнең белән сөйләшеп торганда намаз вакыты керсә, ул сөйләшүен ташлап, әйтерсең лә безне белмәгән кеше кебек намазга китә иде. Ул (с.г.в.), намазда кешенең тәне белән йөрәге бергә булмаган кешегә Аллаh карамый дия иде. Гали (р.г.) намаз вакыты кергәч, калтырый башлый һәм битенең төсе үзгәрә иде, ул моның сәбәбен якындагыларга аңлатып: “Бик җаваплы вакыт җитте, Аллаh бу җаваплылыкны күк, җир, тауларга тәкъдим итте, әммә алар куркып кабул итмәделәр, ә мин аны кабул иттем”,– диде. Ә Гомәр ибн Хаттабның (р.г.) намазга басар алдыннан тезләре һәм тешләре бер- берсенә тиеп калтырый иде. Аннан сорадылар: “Нәрсә бу?”, –дип. Ул җавап кайтарды: “Амәнәтне кире алу вакыты килеп җитте, мин моны нинди дәрәҗәдә башкарачагымны белмим”. Гали ибн Хәсәннең тәһарәт алганнан соң йөзе саргайгач, якыннары сәбәбен сорадылар. Ул җавап итеп әйтте: “Беләсезме, минем кем каршына барганны?”. Ә ибн Әюбне намаз вакытында шөпшә тешләдә һәм аннан кан чыкты, әмма ул моны сизмәдә. Моның серен ул: “Шөпшә тешләвен Бөек Хуҗа каршында, кайчан аның артында үлем фәрештәсе, сул ягында тәмуг, ә аяк астында сират булган кеше сизәчәкме? ”. Мондый мисалларны күп китерергә була. (Ә без болардан бик ерак торабыз, кызганычка каршы).
“Эчеңнән генә Раббыңны зекер ит түбәнчелек вә курку илә һәм сөйләшүдә кычкырудан түбәнрәк тавыш белән зекер ит, иртәләрдә вә кичләрдә гафилләрдән булма!”.). **(7: 205).**
“Дәреслектә Мин – Аллаh, юк коллык кылырга яраклы Иләһә, мәгәр Мин генә, Миңа гына гыйбадәт кыл вә Мине зекер итәр өчен намаз укы!”. **(20:14)**
Намаз укучы өчен намаз бу дөнья һәм ахирәт көнендә зур бер корал булып тора.
**Гөнаһлардан арыну.** Пәйгамбәребез (с.г.в.): “Әгәр кеше җиренә җиткереп тәһарәт алса һәм көненә биш вакыт намаз укыса, аның гөнаһлары агачтагы яфраклар коелган кебек юкка чыгалар.
**Шифа.** Хәдис: Намаз укыгыз, аннан дәва табарсыз.
**Явызлыктан саклаучы.** Намаз бозыклык, оятсызлык, гөнаһка төшүдән, имансызлыкка илтүче юллардан саклый.
**Кыямәт көнендә шаһитлек бирәчәк.**
Болардан чыгып шуны әйтәсе килә, намаз безнең бу дөнья һәм мәңгелегебез өчен иң мөһиме. Безнең җаныбызга тынычлык биреп, күңелләребезгә нур өсти. Мөселманны мәгънәсезлектән чыгаручы зур бирем булып тора.

**СӨМБЕЛ ШӘРИФУЛЛИНА,**
КФУ студенты.
**(Интернет материалларын кулланып әзерләнде).**

# ЯШЬЛЕКНЕҢ КАДЕРЕН БЕЛИК!

**Яшьлек – ул шундый вакыт, Аллаһы Тәгалә тарафыннан кешенең төрле яклатып сыналган чагы. Ул көч һәм энергиягә бай, әмма дә ләкин дөнья рәхәтлекләре, байлыклары нәфесне төрле яклатып үзенә тартып тора.**

Ә шайтан шуннан файдаланып, кешене туры юлдан тайпылдыру, Аллаһка гыйбадәт кылудан тыю өчен үзенең зур көчен куя. Күпләр шайтанның ятьмәсенә эләккәннәрен сизми дә калалар һәм аның күрсәтмәләре буенча эш кыла башлыйлар.

Без күреп торабыз: бүгенге көндә күпчелек яшьләр җан тынычлыгын, булсын ул авыл яшьләре, булсын шәһәр яшьләре, дискотека, концерт, кино, ресторан, кафе, сауна, төрле клублардан табалар. Шулай итеп алтын, бриллианттан да кадерлерәк вакытларын әрәм итәләр. Күпләрнең киенү, сөйләшү, тормышта үз-үзен тоту рәвеше гомумән исламнан ерак тора. Гыйлем алып Коръән һәм сөннәт буенча яшәргә тырышучылар, кызганычка каршы, сирәк.

Кайбер яшьләр өстән генә фикер йөртеп әйтәләр: нишләп Аллаһ безгә үзебез теләгән бөтен гамәлләрне дә кылырга рөхсәт итмәде? Боларның шулай уйлауларын бәләкәй балалар белән чагыштырырга булыр иде. Аларга да бит әти-әниләре көне буе уйнарга рөхсәт итми, ә уеннан тыш нәрсә белән булса да шөгыльләнүен контрольдә тотып тора: дәрес хәзерләү, өйдәге эшләрдә булышу һ.б. Әти-әни баланы тәрбияли, ашата-эчертә, киендерә, ә авырып китте исә, ниндидер тәмсез дарулар, уколлар белән дәвалый. Әмма күп балалар бу тырышлыкларны күрми дә, аңлап та җиткерми. Ә күпләр дошман итеп күрәләр. Әлбәттә үсеп җиткәч, тәҗрибә туплангач, алар ата-ананың нинди зур көч түккәнен, хәтта үзләреннән дә ныграк кайгырган икәнлеген төшенәләр. Ә Аллаһы Тәгалә безгә әти-әнигә караганда да күпкә мәрхәмәтлерәк. Шуны истән чыгармаска кирәк, Аллаһ юлында барып без бу дөньяда гына түгел, мәңгелек бәхеткә дә ирешәбез. Аллаһы Тәгалә Коръәндә әйтә: “Сезнең кулыгызда булган нәрсәләр һәммәсе бетәчәк, әмма Аллаһ кулында булган нәрсәләр мәңгегә каладыр. Аллаһ кушканча яшәп вә Ул кушканча дин тотарга бөтен авырлыкларны күтәрүче сабыр мөэмин-



нәргә, әлбәттә, кылган изге гамәлләренең яхшырагы белән бүләкләрбез.” (16:96, Ногмани тәфсире)

Без күрмибезме әллә, Аллаһ тыйган гамәлләрне кылучыларның ахыргы сулышлары ничек тәмамланганын. Аллаһы Тәгалә Коръәндә әйтә: “Аларга ахирәтнең олуг газабыннан элек дөньяда да, әлбәттә, газапны татытачакбыз, шаять калганнары тәүбә итеп иманга килерләр.” **(32:21, Ногмани тәфсире)**.

Аллаһы Тәгалә безгә тәмле тәгамнар белән ризыклану, матур кием кию, бу дөньяның матурлыклары белән ләззәтләнү, ял итүне бер дә тыймый. Әлбәттә шәригать кануннарыннан чыкмаганда. Аллаһы Тәгалә Коръәндә әйтә: “Әйт: “Аллаһы тәгалә бәндәләренә биргән зиннәтле киемнәрне кем хәрам кылды вә ризыктан пакь, ләззәтле булганнарын кем хәрам кылды?” Әйт: “Ул зиннәтле киемнәр вә хуш булган ризыклар дөньяда вакытта иман китергән мөэминнәргә, кыямәт көнендә махсус мөэминнәргә, кәферләргә мәхрүмнәрдер”. Әнә шулай аятьләребезне ачык аңлатабыз хакны белгән кешеләр өчен.” **(7:32, Ногмани тәфсире).**

Күп кешеләр омтылган дөнья байлыклары миражга тиң, тамагыбыз кипкәндә ул безгә ерактан су кебек күренә, ә инде янына барыйк дисәк без анда бер нәрсә дә булмаганын күрәбез. Яшьләр гыйбадәт кылуны, Аллаһ кушканча яшәүне соңга, картайгачка калдырмасалар иде. Яшь вакытта кылган гыйбадәт яшь була, карт вакытта кылган гыйбадәт карт була. Яшь вакытта алган тәрбия, белем ташка уеп язган кебек, ә картайгач алган белем суга язу белән бер дип юкка гына әйтмәгәннәрдер. Шунысы бар бит әле: кем картлык яшенә барып җитә? Тирә-ягыбызга күз салсак, күпме безнең янда картлар? Кабер ташларына карагыз, туган һәм үлгән елларын һәм сез ышанырсыз күпләрнең картайганчы бу дөньядан китеп барганнарына. Шуның өчен дә гыйбадәт кылуны картлыкка калдыру ахмаклык булыр иде. Ризаэтдин Фәхретдин дә әйткән бит: “Акылы камил булган кеше дингә килмичә калмас”,– дип. Әллә без яшьләрнең акыллары камил түгелме? Алай дисәң, һәр икенче кешедә диплом бар бүген. Әле берәү генә дә түгел.

Бу дөньяда бөтен әйбер капма-каршысы белән: яхшылык–начарлык, сөенеч–кайгы, җиңеллекләр–авырлыклар, сәламәтлек–чир, яшьлек–картлык, көлү–елмаю, белемлелек–наданлык, байлык–ярлылык, ямьсезлек–матурлык, дәрәҗә–түбәнлек, ярату– нәфрәт һ.б. Ә киләсе дөньяда шушыларның барысы өчен дә җавап бирәсе булачак.

Безнең пәйгамбәребез инде кечкенә вакытыннан ук үзенең яхшы холыгы белән аерылып тора иде. Аның янында булган, исламны таратырга зур көч куйган сәхәбәләр дә–яшьләр. Аларның күбесенә нибары 17-35 яшьләр тирәсе иде. Яшьлектә кылган гыйбадәтнең зур дәрәҗәсе турында пәйгабәребез әйтеп китте: Кыямәт көнендә Аллаһның күләгәсеннән башка күләгә булмаганда, бары тик җиде төрле кеше генә Аллаһның күләгәсе астында булыр, шуның берсе бәләкәйдән үк гыйбадәттә булган яшь кеше.

Тагын бер хәдисендә әйтә: “Биш әйберне вакытында файдалан: яшьлегеңнән картлык, сәламәтлегеңнән авыру, байлыгыңнан хәерчелек, буш вакыттан мәшәкать, тормышыңнан үлемең килгәнче”.

Вакытыбызны Аллаһ Тәгалә үзе риза булырдай итеп үткәрергә насыйп итсен. Әмин.

**СӨМБЕЛ ШӘРИФУЛЛИНА,**
КФУ студенты.

**“Биш әйберне вакытында файдалан: яшьлегеңнән картлык, сәламәтлегеңнән авыру, байлыгыңнан хәерчелек, буш вакыттан мәшәкать, тормышыңнан үлемең килгәнче”.**

# МӘДРӘСӘ КӨТӘ



**Бисмилләһир-рахмәнир-рәхим! Бөтен галәмнәрнең тәрбиячесе булган Аллаһыбызга биниһая хәмед-сәна, шөкераналарыбыз булса иде!**

Мин быел мәдрәсәнең икенче курсын тәмамладым. Аллага шөкер, үзем өчен бик тә кирәкле дин белеме тупладым. Аллаһы Тәгалә һәр мөселман кешесенә гыйлем алуны фарыз итеп билгеләгән. Чөнки белеме булган, фикер йөртә белгән кеше генә Ислам диненең асылын чын-чынлап аңлый һәм йөрәге белән кабул итә ала. Акылын һәм зиһенен һәрчак камилләштерүгә омтылган кеше генә дингә фанатларча бирелмичә, ихлас күңеле белән Аллаһыга якынрак була. Күп кешедән ишеткәнем бар: "Мин Аллаһка ышанам, әмма мәчеткә дә, мәдрәсәгә дә йөрмим, чөнки минем гөнаһым юк!"– диләр. (Гомере буе кибеттә эшләгән, зина кылып йөргән һ.б. шундый күп сәбәпләрне әйтәләр). Анда гөнаһларын юар өчен йөрмиләр бит. Без, кешеләр, барыбыз да гөнаһсыз булмыйбыздыр, Аллаһы Тәгалә үзе кичерсен. Минем курсташларым, бар да укымышлы, яхшы кешеләр–врачлар, укытучылар... Әгәр дә гөнаһ кылган булып, тәүбә итсәләр, бу бит бик тә сөенечле хәл. Димәк, дингә килгәннәр, начар юлда түгел бит. Мин үзем дә Аллаһыга чын күңелдән ышана идем. Тик мәгънәсен аңлап бетереп түгел. Шушы мәдрәсәдә белем ала башлагач Аллаһының берлегенә һәм барлыгына тагын да ышаныч артты. Аллаһы Тәгалә мине бервакытта да ярдәменнән ташламый.
Кайберәүләр: "Хәтерем юк, догаларны ятлый алмыйм,"–диләр. Мин–бер ел эчендә сигез тапкыр наркоз алган кеше. Аллаһы Тәгалә үзе ярдәм итә ул. Диндә көчләү юк, өндәү генә бар. Бернидән курыкмыйча, сөенеп килегез безнең мәдрәсәгә гыйлем алырга. Мәктәптәге кебек анда икеле куймыйлар. Киләбез, мөгаллимнәребезнең сөйләгәннәрен тыңлыйбыз, кирәклесен язабыз, өйгә кайткач укып чыгып, алган гыйлемебезне йөрәгебезгә тагын да ныгытып куябыз. "Имтихан бирәсе икән анда,"– диючеләргә, шуны әйтер идем: ул бит алган гыйлемебезне яңадан искә төшерү генә. Монда барысына да өйрәтәләр, үз җае белән барысы да килә. Мәдрәсәдә без җан тынычлыгы һәм сихәт алып кайтабыз. Эштән соң арып-талып килсәк тә, бөтен гәүдәгә җиңеллек тарала. Дин юлында булган кешене, башында яулык булса, барлык кеше хөрмәт итә.
Гыйлемне үзебез өчен генә түгел, Аллаһы ризалыгы өчен өйрәник. Күп уйланырга, аз сөйләргә гадәтләник. Кирәкмәс сүз сөйләшмик һәм сүзләребез файдалы, тәэсирле булса иде!

**МӨНИРӘ НӘБИУЛЛИНА,**
2 курс талибәсе.

## Сорау җавап

### УРАЗАНЫ КАЗА КЫЛУ

**С: Рамазан аеның каза уразаларын рамазан ае беткәч үк каза кылырга кирәкме?**
Ж,: Бу шарт булып килми, кайчан теләсә шунда каза кылырга мөмкин.
**С: Әгәр кеше каза кылуын икенче рамазан ае башына кадәр сузып килсә, аңа нишләргә?**
Ж,: Әүвәл башланган рамазанның уразасын тотарга, аннан соң калдырган көннәре өчен каза кылырга тиеш.
**С: Бер кеше үлгәннән соң рамазан аеннан каза уразалары калган булып, үзенең милкеннән кәффарәт түләргә васыять итеп калдырган булса, аның вәкиленә нишләргә?**
Ж,: Мондый васыять үлгән кешенең милкеннән 1/3 өлешен алып түләнелә. Һәрбер калдырган көн өчен ярты сагъ бодай яки бер сагъ арпа, хөрмә белән бер мескенне ашатырга кирәк.

### НӘФЕЛ УРАЗАЛАРЫ

**С: Нинди көннәрдә нәфел уразаларын тоту тыела?**
Ж,: Елның биш көнендә: ураза һәм корбан гаетендә, корбан гаете артыннан килүче 3 көндә нәфел уразасын тотарга ярамый.
**С: Нинди дә булса нәфел уразаларының башка уразалар алдында фазыйләтләре бармы?**
Ж,: Әйе, бар. Һәм бу хакта хәдисләрдә әйтелә.
Гайшәдән риваять ителә: «Аллаһның рәсүле (с.г.в.) дүшәмбе һәм пәнҗешәмбе көннәрендә ураза тотты». (Тирмизидән китерелә.) Шулай ук Әбү Һөрәйра Аллаһның рәсүле (с.г.в.) тулган ай көннәрендә өйдә дә,вә сәфәрдә дә ураза тотуын риваять итә. (Ән-Нәсаидән китерелә). Әбү Әюп әл-Ансари риваять итә: «Аллаһның рәсүле (с.г.в..) әйткән: «Кем Рамазан аенда һәм шәүвәл аеның 6 көнендә ураза тотса, гомере буе ураза тоткан кебек булыр».

## Укырга чакырабыз

### Мамадыш мәдрәсәсенә рәхим итегез!

Татарстан Җөмһүрияте Мөселманнары Диния Нәзарәте каршындагы Мамадыш мәдрәсәсе 2012-2013 уку елына шәкертләр туплый.
Белгечләр әзерләү көндезге һәм кичке уку рәвешендә алып барыла.
Көндезге бүлеккә яше 14тән дә ким булмаган егетләр кабул ителә. Шәкертләр мәдрәсә тулай торагында яшәү урыны һәм көненә өч тапкыр ашау-эчү белән тәэмин ителәләр. Уку вакыты – өч ел. Урта белем алу икенче санлы лицей базасында алып барыла. Мәдрәсәне тәмамлаганнан соң шәкертләргә квалификация комиссиясе карары нигезендә тиешле белгечлек алу турында диплом бирелә.
Укырга керү өчен кабул итү комиссиясенә түбәндәге документларны тапшырырга кирәк:
**1) Гариза. 2) Белем турында таныклык. 3) 086-формасында сәламәтлек турында белешмә. 4) Паспорт (копия). 5) 3х4 үлчәмендә 4 фотосурәт. 6) №26 формасында шәхси медицина картасы**
**Документлар 30 августка кадәр кабул ителә.**
*Намаз укырга өйрәнергә һәм дин белемен үзләштерергә теләүчеләр өчен мәдрәсәдә кичке уку бүлеге һәм читтән торып уку бүлеге эшли. Бу бүлекләргә хатын-кызлар һәм ир-егетләр кабул ителә. Яшь чиге куелмаган.*
*Безнең адрес: Татарстан Республикасы, Мамадыш шәһәре, М. Җәлил урамы 8/28,*
**Телефоннар: 3-19-17, 89172802391**

**Газетада Аллаһы Тәгаләнең Бөек исемнәре булганга күрә, аны саклап тотуыгыз сорала**

Баш мөхәррир: Хәбибуллин А.М. Мөхәррир урынбасары: Хәбибуллина Э.Р.
Дизайн һәм верстка: Мингалиева Ф.Н. Җаваплы сәркатип: Спиридонова А.С.
Безнең адрес: Мамадыш шәһәре, Муса Җәлил урамы,8/28. mamadysh-medrese@mail.ru. Газета "Татмедиа" ААҖнең Мамадыш муниципаль районы"Нократ" мәгълүмат-матбугат филиалында басылды. Тираж татар телендә 250 данә.